# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Түбән Сукаеш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**15 ноябрь 2025 ел** **№ 1**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 20.03.2025 ел №33-ФЗ Федераль законның 45,69 статьясы , 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Уставы нигезендә 2025 елның 15 ноябрендә, түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гаражданнар җыенының йомгаклау протоколы төзелде:

«Сез 2026 елда Сукаеш авыл җирлеге Түбән Сукаеш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, махсус хәрби операциядә катнашучылар, аларның гаилә әгъзалары, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узучы гражданнардан тыш 400 сум күләмендә һәм 80 яшьтән өлкәннәрдән 200 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су алу насосын сатып алу).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия 55 гражданнар җыенында катнашучы теркәлгән, халык җыенында катнашып тавыш биргән гражданнар саны 31.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен 31,

«КАРШЫ» позициясе өчен 0 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Түбән Сукаеш торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – гамәлдә (дөрес) дип таныrга.
2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул ителгән дип таныrга:

«Сез 2026 елда Сукаеш авыл җирлеге Түбән Сукаеш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, махсус хәрби операциядә катнашучылар, аларның гаилә әгъзалары, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узучы гражданнардан тыш 400 сум күләмендә һәм 80 яшьтән өлкәннәрдән 200 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су алу насосын сатып алу).

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Сукаеш авыл җирлеге мәгълүмати стендларында түбәндәге адреслар буенча: Зур Сукаеш авылы, Совет ур. 30 йорт, Түбән Сукаеш авылы, Кызыл юл ур. 32 йорт, һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Сукаеш авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Сукаеш авыл җирлеге башлыгы: Закирова З.Җ.